ИНСПЕКЦИЯ
ГОСУДАРСТВЕННОГО
СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШЕН
КҮЗӘТҮ ИНСПЕКЦИЯСЕ

ПРИКАЗ БОЕРЫК

Казан ш.

15.02.2016 № 11

Татарстан Республикасының
Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә
Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык
хезмәткәрләре тарафыннан вазифаи
вәкаләтләрне үтәгәндә мәнфәгатьләр
каршылыгына китерә торган яки
китерергә мөмкин булган шәхси
кызыксынучанлык барлыкка килү
турында хәбәр итү тәртибе
хакында

2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы көрәш турында” № 273-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының 2015 елның 22 декабрендәге “Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазифаларын, федераль дәүләт вазифаларын биләүче затлар һәм бүтән затлар тарафыннан вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турында һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында” № 650 Указы нигезендә

Б О Е Р А М:

1. Кушымта булып килүче Татарстан Республикасының Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турында нигезләмә расларга.

2. Инспекциянең дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә, Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендәге дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше

һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиягә кушымта булып килүче үрнәктә (2 кушымта) язмача рәвештә вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килүнең барлык очраклары турында хәбәр бирергә.

3. Дәүләт хезмәте мәсьәләләре һәм кадрлар сәясәте буенча бүлеккә Инспекция хезмәткәрләрен имзалатып таныштырырга һәм шушы боерыкны Инспекциянең рәсми сайтында "Коррупциягә каршы көрәш" бүлегендә урнаштырырга.

4. Хокукый идарәнең юридик бүлегенә шушы боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынуын тәэмин итәргә.

5. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту җаваплылыгын үз өстемә алам.

Башлык В.А. Кудряшов

Татарстан Республикасы
ДТК инспекциясенең
2016 елның “15”02
№ 11 боерыгына кушымта

**Татарстан Республикасының Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турында нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмә Инспекциядә Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын биләүче затлар тарафыннан вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибен билгели.

2. Гражданлык хезмәткәрләре Россия Федерациясенең коррупциягә каршы көрәш турындагы законнары нигезендә Татарстан Республикасының Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе башлыгына вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итәргә, шулай ук мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмый калу яисә җайга салу буенча чаралар күрергә бурычлы.

Хәбәр язмача, 1 кушымтада китерелгәнчә, вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында белдерүнамә рәвешендә рәсмиләштерелә.

3. Инспекция башлыгына җибәрелгән белдерүнамәләр, аның әмере буенча, Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендәге дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиянең рәисе булган Инспекция башлыгының беренче урынбасары (алга таба – Комиссия рәисе) тарафыннан карап тикшерелә ала.

Инспекция башлыгының яки Комиссия рәисенең карары буенча белдерүнамәләр гражданлык хезмәткәрендә вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү фактын тикшерүне оештыру өчен дәүләт хезмәте мәсьәләләре һәм кадрлар сәясәте буенча бүлеккә, коррупция һәм башка төрле хокук бозуларны кисәтү эше өчен җаваплы булган затка тапшырылырга мөмкин.

Белдерүнамәләрне беренчел карап тикшерү барышында дәүләт хезмәте мәсьәләләре һәм кадрлар сәясәте буенча бүлекнең вазифаи затлары, коррупция һәм башка төрле хокук бозуларны кисәтү эше өчен җаваплы

булган затлар билгеләнгән тәртиптә белдерүнамәләрне җибәрүче гражданлык хезмәткәрләреннән анда бәян ителгән шартлар буенча аңлатмалар алырга һәм билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясенең Татарстан Республикасы буенча Пенсия идарәсенә, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Социаль яклау идарәсенә, кызыксынган оешмаларга гарызнамәләр җибәрергә, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә һәм Федераль дәүләт теркәве, кадастры һәм картографиясе хезмәтенең (Росреестр) Татарстан Республикасы буенча идарәсенә гарызнамәләр җибәрелү хакында үтенеч язуы белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

4. Дәүләт хезмәте мәсьәләләре һәм кадрлар сәясәте буенча бүлекнең вазифаи затлары тарафыннан белдерүнамәләрне беренчел карап тикшерү нәтиҗәләре буенча аларның һәркайсы өчен нигезле бәяләмә әзерләнә.

Беренчел карап тикшерү барышында алынган белдерүнамәләр, бәяләмәләр һәм бүтән материаллар Инспекция башлыгына яки Комиссия рәисенә белдерүнамәләр кергән көннән башлап җиде эш көне дәвамында тапшырыла.

Шушы Нигезләмәнең 3 пунктындагы өченче кызыл юлда күрсәтелгән гарызнамәләр җибәрелгән очракта белдерүнамәләр, бәяләмәләр һәм башка материаллар Инспекция башлыгына белдерүнамәләр кергән көннән башлап 45 көн дәвамында тапшырыла. Күрсәтелгән вакыт озайтылырга мөмкин, ләкин 30 көннән дә озаграк чорга түгел.

5. Белдерүнамәләрне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Инспекция башлыгы тарафыннан түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

а) Инспекциянең белдерүнамәне җибәрүче гражданлык хезмәткәре тарафыннан вазифаи бурычлар үтәлгәндә мәнфәгатьләр каршылыгы юк икәнлеген танырга;

б) Инспекциянең белдерүнамәне җибәрүче гражданлык хезмәткәре тарафыннан вазифаи бурычлар үтәлгәндә шәхси кызыксынучанлыкның мәнфәгатьләр каршылыгына китерүен яки китерергә мөмкин булуын танырга;

в) Инспекциянең белдерүнамәне җибәрүче гражданлык хезмәткәре тарафыннан мәнфәгатьләрне җайга салу турындагы таләпләрнең үтәлмәвен танырга.

6. Шушы Нигезләмәнең 5 пунктындагы “б” пунктчасында каралган карар кабул ителгән очракта, Россия Федерациясе законнары нигезендә, Инспекция башлыгы мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмый калу яки җайга салу буенча чаралар күрелүен тәэмин итә, яисә белдерүнамәне җибәргән гражданлык хезмәткәренә шундый чараларны күрергә киңәш итә.

7. Нигезләмәнең 5 пунктындагы “в” пунктчасында каралган карар кабул ителгән очракта Инспекция башлыгы Комиссия рәисенә утырыш үткәрү турында йөкләмә бирә.

8. Комиссия белдерүнамәләрне карап тикшерә һәм Татарстан Республикасының Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә Татарстан

Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан вазифаи вәкаләтләр үтәлгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турында нигезләмә нигезендә алар буенча карарлар кабул итә.

9. Комиссия утырышының беркетмәсе ахыргы карарны кабул итү өчен Инспекция башлыгына җибәрелә.

Татарстан Республикасының Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турында нигезләмәгә карата 2 кушымта

________________________________
(танышу турында тамга)

Татарстан Республикасының
Дәүләт төзелешен күзәтү
инспекциясе башлыгына

кемнән ______________________________
_____________________________________
(Ф.И.А., биләгән вазифасы)

**Вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында**
**БЕЛДЕРҮНАМӘ**

Вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә миндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итәм (кирәклесе астына сызарга).

Шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү өчен нигез булган шартлар:
__________________________________________________________________
__________________________________________________________________

Шәхси кызыксынучанлык аларның үтәлешенә йогынты ясый яки ясарга мөмкин булган вазифаи вәкаләтләр ______________________________________
__________________________________________________________________
__________________________________________________________________

Мәнфәгатьләр каршылыгын бетерү яки җайга салу буенча тәкъдим ителә торган чаралар:_____________________________________________
_________________________________________________________________

Шушы белдерүнамәне карап тикшергәндә Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендәге дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссия утырышында шәхсән катнашырга ниятлим / ниятләмим (кирәклесе астына сызарга).

| | | |
|---|---|---|
| __________ | ________________________ | ________________________ |
| (дата) | (белдерүнамә җибәргән затның имзасы) | (имзаның аңлатмасы) |